# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Спас муниципаль районының Иж-Борискино һәм Урта Йорткүл авыл җирлекләрен үзгәртеп кору һәм «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 30 маенда
кабул ителде

**1 статья**

Спас муниципаль районы составындагы «Иж-Борискино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген һәм «Урта Йорткүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген әлеге җирлекләрдәге халыкның аларның вәкиллекле органнары аша белдерелгән ризалыгы нигезендә күрсәтелгән җирлекләрне административ үзәге Урта Йорткүл авылы булган «Урта Йорткүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенә (алга таба – яңа төзелгән «Урта Йорткүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге) берләштерү юлы белән үзгәртеп корырга.

**2 статья**

1. Яңа төзелгән «Урта Йорткүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең беренче чакырылыш вәкиллекле органы депутатларының һәм беренче башлыгының вәкаләтләре чорын ике ел дип билгеләргә.

2. Яңа төзелгән «Урта Йорткүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең беренче чакырылыш вәкиллекле органындагы депутатлар санын җиде кеше тәшкил итә дип билгеләргә.

3. Яңа төзелгән «Урта Йорткүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына сайлауларны билгеләү, сайлауларны әзерләү һәм уздыру законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

**3 статья**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 34 статьясындагы 5 өлешендә каралган тәртиптә җирле референдумда кабул ителә торган яңа төзелгән «Урта Йорткүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары структурасы турындагы карарда башкасы билгеләнмәгән булса, түбәндәгеләрне билгеләргә:

1) яңа төзелгән «Урта Йорткүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең беренче башлыгы әлеге муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан яшерен тавыш бирү юлы белән үз составыннан сайлап куела.

Яңа төзелгән «Урта Йорткүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең беренче чакырылыш вәкиллекле органы депутаты, вәкиллекле орган депутатларының билгеләнгән санынннан яртысыннан артыграгы аны хуплап тавыш бирсә, бу муниципаль берәмлекнең сайлап куелган башлыгы дип санала.

Яңа төзелгән «Урта Йорткүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең башлыгын сайлап куйганчы, бу муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы утырышын вәкиллекле органның яше буенча иң өлкән депутаты ача һәм алып бара;

2) яңа төзелгән «Урта Йорткүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең сайлап куелган башлыгы бу муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе вәкаләтләрен башкара.

**4 статья**

«Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (III өлеш); 2008, № 7 (II өлеш); 2009, № 7-8 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:

а) бишенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

б) унбишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Урта Йорткүл авыл җирлеге: Урта Йорткүл (административ үзәк), Иж-Борискино, Урманасты Йорткүл, Кырый Йорткүл, Фадеевка авыллары;»;

2) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Спас муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләрс чикләрсн билгеләү һәм
аларның статусы турында" Татарстан
Республикасы Законына
1 нче кушымта

# "Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керә торган муниципаль берәмлекләрнең чикләре карта-схемасы




Шартлы билгеләр

- Татарстан Республикасы чиге
- муниципаль район чиге
- тоташу ноктасының тәртип саны
- жирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге

Муниципаль районның
чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 9(3)-1(34) | - Тәтеш муниципаль районы |
| 1(34)-20(33) | - Кама Тамагы муниципаль районы |
| 20(33)-24(32) | - Лаеш муниципаль районы |

«Спас муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге составына керә торган
шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Болгар шәһәре |
| 2 | Аграмак авыл җирлеге |
| 3 | Антоновка авыл җирлеге |
| 4 | Бураково авыл җирлеге |
| 5 | Әҗмәр авыл җирлеге |
| 6 | Иске Рәҗәп авыл җирлеге |
| 7 | «КИМ» авыл җирлеге |
| 8 | Кызыл Бистә авыл җирлеге |
| 9 | Кузнечиха авыл җирлеге |
| 10 | Куралово авыл җирлеге |
| 11 | Никольский авыл җирлеге |
| 12 | Полянка авыл җирлеге |
| 13 | Приволжский авыл җирлеге |
| 14 | Урта Йорткүл авыл җирлеге |
| 15 | Өчкүл авыл җирлеге |
| 16 | Чәчәкле авыл җирлеге |
| 17 | Ямбакты авыл җирлеге |

»;

3) 4 нче кушымтада:

а) икенче абзацта «Иж-Борискино,» сүзен төшереп калдырырга, «КИМ,» сүзеннән соң «Урта Йорткүл,» сүзләрен өстәргә;

б) дүртенче абзацта «Иж-Борискино» сүзен «Урта Йорткүл» сүзләренә алмаштырырга;

в) бишенче абзацта «Иж-Борискино авыл җирлеге» сүзләрен «Урта Йорткүл авыл җирлеге» сүзләренә алмаштырырга, «Иж-Борискино авыл җирлекләре» сүзләрен «Урта Йорткүл авыл җирлекләре» сүзләренә алмаштырырга;

4) 5 нче кушымтада:

а) икенче абзацта «Иж-Борискино,» сүзен төшереп калдырырга;

б) бишенче абзацта «Иж-Борискино» сүзен «Урта Йорткүл» сүзләренә алмаштырырга;

в) алтынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

г) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Антоновка авыл җирлеге чиге Урта Йорткүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 29 нчы тоташу ноктасыннан алып 5,7 км төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман утыртмаларын, Бездна елгасын, Конопляный күленнән 1,6 км төньякта Антоновка – Кузнечиха автомобиль юлын кисеп үтеп, алга таба шул ук юнәлештә 1,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 700 м басу юлы буенча Антоновка, Никольский, Урта Йорткүл авыл җирлекләре чикләре тоташкан

урында Урта Йорткүл авылыннан 2,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 31 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

5) 7 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

6) 12 нче кушымтада:

а) икенче абзацта «Иж-Борискино,» сүзен төшереп калдырырга;

б) дүртенче абзацта «Иж-Борискино, Кузнечиха» сүзләрен «Кузнечиха, Урта Йорткүл» сүзләренә алмаштырырга;

в) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кузнечиха авыл җирлеге чиге Урта Йорткүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 35 нче тоташу ноктасыннан алып 1,1 км көньяк-көнбатыш юнәлештә, алга таба 2,6 км төньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк ягы буйлап уза, аннары 1,0 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре һәм чокыр буйлап урман кырыена кадәр бара, юнәлешен үзгәртмичә, 1,8 км урман массивының көнбатыш ягыннан уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба борыла һәм 1,3 км озын чокырның көнбатыш кырые буйлап басу юлына кадәр, аннары 1,8 км төньяк-көнбатышка таба басу юлы буйлап, шуннан соң 2,1 км көньякка таба басу юлы буйлап грунт юлга кадәр һәм аның буенча 200 м төньяк-көнбатышка таба 33 нче тоташу ноктасына кадәр бара.»;

г) сигезенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

7) 17 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең
һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
17 нче кушымта

**Спас муниципаль районының**
**«Урта Йорткүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Урта Йорткүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Урта Йорткүл авыл җирлеге Аграмак, Антоновка, Кузнечиха, Никольский авыл җирлекләре, Әлки муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе белән чиктәш.

**Спас муниципаль районының**
**«Урта Йорткүл авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге территориясе чиге**

Урта Йорткүл авыл җирлеге чиге Ульяновск өлкәсе белән чиктәш җирдә Кузнечиха, Урта Йорткүл авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Кузнечиха авылыннан 4,9 км көнбатышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Никольский, Урта Йорткүл авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Кырый Йорткүл авылыннан 4,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Урта Йорткүл авыл җирлеге чиге Никольский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Антоновка, Никольский, Урта Йорткүл авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кырый Йорткүл авылыннан 2,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 31 нче тоташу ноктасыннан алып 2,0 км көньяк-көнбатышка таба урман полосасының төньяк-көнчыгыш ягы буйлап, алга таба 3,1 км көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, аннары 200 м төньякка таба басу юлы буйлап 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Урта Йорткүл авыл җирлеге чиге Антоновка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Аграмак, Антоновка, Урта Йорткүл авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Фадеевка авылыннан 2,2 км төньякта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасыннан алып 5,7 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман утыртмаларын, Бездна елгасын, Конопляный күленнән 1,6 км көньякта Антоновка – Кузнечиха автомобиль юлын кисеп үтеп, алга таба шул ук юнәлештә 1,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 700 м басу юлы буенча 31 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Урта Йорткүл авыл җирлеге чиге Аграмак авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Аграмак, Урта Йорткүл авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы чикләре тоташкан урында Фадеевка авылыннан 2,2 км төньякта урнашкан 28 нче тоташу ноктасыннан алып 150 м төньяк-көнбатышка таба Татар Такталысы – Фадеевка автомобиль юлының көньяк-көнбатыш ягы буйлап 29 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Урта Йорткүл авыл җирлеге чиге Әлки муниципаль районы белән чиктәш җирдә 28 нче тоташу ноктасыннан алып көньякка таба Спас муниципаль районы чиге буйлап Кузнечиха, Урта Йорткүл авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы чикләре тоташкан урында Урманасты Йорткүл авылыннан 5,1 км көнчыгышта урнашкан 35 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Урта Йорткүл авыл җирлеге чиге Кузнечиха авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 35 нче тоташу ноктасыннан алып 1,1 км көньяк-көнбатыш юнәлештә, алга таба 2,6 км төньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк ягы буйлап уза, аннары 1,0 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре һәм чокыр буйлап урман кырыена кадәр бара, юнәлешен үзгәртмичә, 1,8 км урман массивының көнбатыш ягыннан уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба борыла һәм 1,3 км озын чокырның көнбатыш кырые буйлап басу юлына кадәр, аннары 1,8 км төньяк-көнбатышка таба басу юлы буйлап, шуннан соң 2,1 км көньякка таба басу юлы

буйлап грунт юлга кадәр һәм аның буенча 200 м төньяк-көнбатышка таба 33 нче тоташу ноктасына кадәр бара.».

**5 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 14 июне
№ 46-ТРЗ